## ЧЕЛТӘР

Сискәнеп уянып китте Нияз. Тәне буйлап ниндидер сәер калтырану йөгереп узганын тойды. Караватчитендә яткан телефонына күз салса, сәгать иртәнге сигез. Эшкә соңга калмыйммы икән соң? Әй, үзенә үзе хуҗа ич ул хәзер. Хәрби эштән китүенә инде бишбылтыр, һаман иртән соңга калудан курка. Тукта әле, ниндидер сәер төш күреп уянды бит. Нәкъ өнендәге сыман иде, хәзер исенә төшерә алмый азаплана. Ә-ә-ә-ә, төшендә хатынын күрде бит. Дөресрәге, элекке хатынын. Кизләүдә тырышып-тырышып кер чайкый, имеш, Миләүшәсе. Үзе ни өчендер кап-карадан киенгән. «Кара инде, кайчаннан бирле юам бу челтәрләрне, һаман чистармыйлар, – диде ул, балалар сыман авызын турсайтып, янәшәсенә килеп баскан Ниязны күргәч. – Хәер, челтәрнең чисталыгы ир-ат кайгысы түгел. Үзем гаепле, вакытында юа алмадым...» Хатынын юатырга теләп, кочаклап алды Нияз. Тик Миләүшә, балык сыман аның кочагыннан шуып чыгып, читкә атылды. «Кагылма миңа! Кит!» – Хатын, җан ачысы белән кычкырып, суга сикерде һәм мизгел эчендә юк булды. Яр читендә пычрак челтәрләр генә өелеп калды. Ни булганын аңларга теләп, Нияз күзләрен уды һәм ... уянып китте.

«Хатирәләр белән яшәп саташам бугай инде», – дип уйлады ир. Юк, болай ярамый. Хәзер салкын душта юынып чыгарга да эшкә чумарга кирәк. Шул вакытта гына элекке тормышының кара шәүләсе артка чигенеп торыр.

Тик ул уйлаганча булып чыкмады. Юынып чыкканда, һаман үз урынында яткан телефоны тавышсыз гына бызылдый иде. Тынычлыкны бозучының номеры таныш булмаса да, Нияз яшел төймәгә басты. «Бу мин – элеккеге хезмәттәшең Радик, – диде трубкадагы тавыш. – Ни... монда авария... Миләүшә, балаларың...» Нияз аны тыңлап бетерә алмады. Телефоны кулыннан төшеп китте.

Машинасын кабызганда да, ыжгырып юлда барганда да, Ниязның башында бер генә уй бөтерелде: «Исән генә булсыннар!..»

Әйе, мәхәббәтен җиргә салып таптаса да, бөтен тормышын астын өскә китерсә дә, тузан бөртеге кадәр дә үпкә сакламый инде ул Миләүшәгә. Аерылышуларына дүрт ел үтүгә дә карамастан, Нияз аны һаман ярата. Әгәр исән-сау калсалар, ты-

нычлыкта калдырып, балаларны дауламас идем, дип, эченнән генә үз-үзенә сүз бирде ир. Әмма хәлләр уйлаганнан мөшкелрәк булып чыкты. Юл читендә яткан машинага күз ташлауга ук, андагыларның исән калу мөмкинлеге бик аз булуын чамалавы авыр түгел иде.

Машинасыннан төшүгә, һәлакәт булган җиргә атылды Нияз. Аны ЮХИДИ хезмәткәрләре туктатты.

– Кызганычка каршы, аларга инде ярдәм итеп булмый. – Тәбәнәк буйлы, чандыр гәүдәле полиция хезмәткәре аның күптәнге танышы Шамил иде. – Кечкенә улыңны «ашыгыч ярдәм» машинасы белән озаттык. Аның да хәле бик авыр. Калганнар…

– Ничек?.. Ничек болай булды соң бу? Рульдә Гамир булганмы? Кем гаепле? – Нияз, куллары белән башын кысып, җиргә чүкте.

– Әйе, Гамир… Машинаны үтәм дип, каршы якка чыккан. Борылыштагы КамАЗны күрмәгән, ахры. Тизлеге дә зур булган. Хәер, боларны сөйләү хәзер инде мәгънәсез. Ул үзе дә… – Шамил, Ниязның янәшәсенә чүгеп, дусларча кочып алды. – Түз, Нияз, түз. Сиңа хәзер ничек авыр икәнен беләбез. Исән калган улың хакына түз.

…Исән калган улың… Аның улымы икән соң ул? Киткәндә әйтте бит Миләүшә: «Икенче бала Гамирдан», – диде. Хәер, барыбер түгелмени инде хәзер?! Ул аны барыбер үзенеке кебек якын күрде. Ике яшенә чаклы, иң нәни, елак вакытында ата булды ич ул аңа. Авырган вакытларында, Миләүшәсе азрак ял итсен дип, төннәр буе күтәреп йөрде. Аерылышканнан соң да, үз улы Маратка бирәр әйбер алып биргәндә, Данилны бервакытта да аерып калдырмады. Данил аңа «әти» дип дәшмәсә дә. Монда баланың бер гаебе дә юк, билгеле. Әнисе сүзеннән ничек чыксын инде ул?! Әйе, ничек тә түзәргә кирәк. Хәзер ул баланың беркеме дә калмады. Нияз аны үз улы кебек үстерергә, җил-давыл тидермәскә тиеш…

Хастаханә ишеге төбендә сәгать буе басып торса да, Данил янына кертмәделәр Ниязны. «Аңа бик авыр операция булды, ул әлегә аңсыз», – диделәр. Кулына, баланың хәлен белешер өчен, телефон номеры язылган кәгазь кисәге тоттырдылар. Башка вакытта булса, табибларны кырыйга этеп, ишекләрне каерып булса да, үз дигәненә ирешер иде Нияз. Булып узган хәлләрдән соң дуамаллану түгел, кешеләр белән сөйләшәсе дә килми иде аның. Эченнән генә улын исән калдыруын үтенеп, Аллага ялварып, башын иеп, фатирына атлады.

Хәмерне авызына алмаганга ике елдан артык вакыт үткән булса да, кайтышлый бер шешә коньяк та алды. Бер-ике йотым эчкәннән соң, рюмкасын бар көченә идәнгә ташлады. Пыяла ватыклары аягын җәрәхәтләде. Тик ир моны сизмәде. Ул үз гомерендә тәүге тапкыр үксеп-үксеп елый иде…

* * *

...Миләүшә белән бер авылда, алай гына да түгел, бер урамда, бер чирәмдә тәгәрәп үсте алар. Кечкенәдән бик дус булдылар. Кыз бик шук, үткен бала иде. Кызлар белән курчак уйнаганчы, малайлар белән кыйнашуны, бакча басарга йөрүне, туп тибүне хуп күрде. Баштарак аны малайлар үз араларына кертергә атлыгып тормасалар да, тиз арада кыз үзенең һич кенә дә алардан ким булмавына ышандырды. Агачка үрмәләгәндә – иң җитезе, чыпчыклар атып уйнаганда, иң төзе булды, ә инде футбол уйнаганда, ул капкада торса, каршы як команданың җиңеләчәге көн кебек ачык иде.

Бергә уйнап, якын дус күреп, кирәк чагында аны яклап йөргән Нияз, азрак үсә төшкәч, Миләүшәгә карата күңелендә башка хис бөреләнүен сизеп алды. Мәктәптә бер парта алдарак утырган кызга төбәлеп, көннәр буе хыялга чумып утыра башлады. Шуның өчен шактый гына «койрык» та эләктергәләде. Тик малайның моңа һич кенә дә исе китми иде. Ул тизрәк дәресләр тәмамлануын, Миләүшәнең букчасын күтәреп, сөйләшә-сөйләшә, өйгә кайтуларын, өй эшен аңламадым дигәнрәк сәбәп табып, аларга кунакка керүне көтә иде. Аның белән сөйләшүдән, хәтта янәшә атлаудан аңлатып бетереп булмаслык тәм таба иде. Кыз исә, киресенчә, үскән саен, Нияздан читләшә барды. Хәзер инде ул күбрәк иптәш кызлары янында кайнаша, алар белән кич утырырга чыга иде. Нияз әллә ничә тапкыр Миләүшәгә үзенең хисләрен ачарга теләде, дәрестә утырган вакытта, мәхәббәт хатлары язды. Тик аларның берсен дә укый алмады кыз. Чөнки Нияз, сәгатьләр буе уйланып, йөрәк рәсемнәре белән бизәп язган хатларын, кызның кесәсенә яки сумкасына салу урынына, чүплеккә ташлады шул. Миләүшә аның хисләреннән көләр дип курыкты. Яшертен генә эчтән янды. Аны үзе өчен буй җитмәслек йолдызга санады.

Бу хәл күпме барыр иде, билгесез, алар белән булган бер вакыйга барысын да үзгәртеп куйды.

Гадәттәгечә, дәресләрдән соң икәүләшеп өйләренә кайтып бара иде алар. Шулчак әллә каян гына зур йонлач эт килеп чыкты һәм, һөҗүмгә җыенгандай, аларга карап, ярсып өрә башлады. «Бирегә кил! – дип кычкырды малай, Миләүшәгә якын агачка күрсәтеп. – Монда ул безгә тия алмаячак». – Һәм җитез генә агач башына үрмәләп менеп китте.

Әллә малайны ишетмәде, әллә куркудан аяклары тыңламас булды – кыз, эткә карап, бер урында катып калды. Тегесе исә шуны гына көткәндәй ырылдап якынлаша башлады. Миләүшә букчасы белән саклангандай итеп, үксеп елый башлады. Агач башына малайлардан да җитез үрмәләгән, бервакытта да күз яше күрсәтмәгән дустыннан моны көтмәгән Нияз бер мәлгә аптырап калды. Тик мизгел эчендә аңа нindидер көч керде, шактый биеккә үрмәләвенә карамастан, кыз янына сикерде һәм эткә ташланды.

Аннан соң ни булганын анык кына хәтерләми, күзләрен ачканда, өендәге караватта ята иде инде Нияз. Ә янәшәсендә … янәшәсендә Миләүшә утыра!

– Мин сине шундый батыр йөрәкледер дип уйламаган идем, – диде ул, аның маңгаеннан сыйпап. – Теге хәшәрәт чүт кенә аяксыз калдырмады бит үзеңне. Рәхмәт, Нияз! Син мине үлемнән саклап калдың! – Кыз, кыюсыз гына, малайны битеннән үбеп алды да, комач кебек кызарынып, урамга чыгып йөгерде.

Соңыннан гына белде Нияз: Миләүшәнең тавышына олылар йөгереп килмәгән булса, ботарлап ташлыйсы булган икән аны әлеге эт. Тик аягының үтереп сызлавына карамастан, Миләүшә «хәшәрәт» дип атаган эткә чиксез рәхмәтле иде Нияз. Чөнки шул көннән соң алар арасында ниндидер сизелмәс җепләр, җылы хисләр сузылды.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң, икесе дә Казанга укырга киттеләр алар. Төрле уку йортларын сайласалар да, һәр көнне күрешеп тордылар.

Укуын тәмамлаганнан соң, егет армиягә китте. Миләүшәсе көтәргә вәгъдә биреп, елап озатып калды. Бер ел вакыт, ике яшь йөрәкне хатлар аша бәйләп, сизелмичә үтеп тә китте.

Армиядән кайтуга, хәрби эшкә урнашты һәм гаилә корырга уйлады Нияз. Ничек итеп Миләүшәгә тәкъдим ясаганын бүгенгедәй хәтерли ул. Инде ничә ел очрашып йөрүләренә карамастан, никтер бик дулкынланды егет. Мәрҗән кашлы йөзек салынган тартмачык чалбар кесәсе аша аягын пешерде. Ак роза чәчкәләренең энәләре кулына кадалып интектерде. Гадәттә, тәкъдимне ресторанда яисә кафеда ясыйлар. Ә Нияз исә сөйгәнен теплоходта йөрергә чакырды. Ничектер балачактан ук «Титаник»тагы сыман су өстендә бер-береңә мәхәббәт аңлату турында хыяллана иде ул.

– Ни булды соң сиңа? – дип гаҗәпләнде кыз, үзен җитәкләп палубага әйдәгән Ниязның куллары калтыравын тоеп. Ә инде егет кесәсендәге тартманы чыгаргач, барысын да аңлап, шатлыгыннан кычкырып көлеп җибәрде.

– Мин риза-а-а! – диде ул, Ниязның авызын ачып ни әйтергә белмичә аптырап калуын күргәч һәм, бармагын тырпайтып, уң кулын егеткә сузды. Әллә каушаудан, әллә мондый кисәк хәрәкәттән инде бармакка кереп утырдым дигән йөзек суга төшеп китте. Нияз аптырап калды.

– Гафу ит, Миләүшә! – диде ул, башын иеп. – Мин сиңа яңаны алып бирермен.

– Әй җаным! – Кызда инде йөзек кайгысы түгел иде. – Кайгырма, туйда кигезерсең әле. Әллә ничә йөзек белән йөрергә ханбикә түгел лә мин. Түлке туйны су өстендә түгел, җирдә үткәрик инде без, яме?!

Егет тә җанланып китте. Сөйгәненең бәхеттән балкыган йөзен күреп, йөзек алыр өчен, ай буе ачлы-туклы йөрүен дә онытты. Ә бит ул: «Арзанлырак йөзек алсам, Миләүшә үпкәләр», – дип уйлаган иде. Әнә нинди икән аның бәгырь кошы. Бәхет өчен ал-

тын-мәрҗәннәр түгел, җан җылысы кирәк икән шул. Кич белән инде алар загска гариза тапшырырга киттеләр.

Туйдан соң тормыш җай гына ага башлады. Тырыш егетне эшендә тиз күреп алдылар. Әкрен генә фатирлы, машиналы булды алар. Миләүшәнең бала көтүен белгәч, Ниязның бәхете тулып ашты, һәр көнне, кош тоткандай, үзалдына шатланып йөри башлады. Хатынының һәр көйсезлеген җайларга, теләген үтәргә әзер торды. Ә алар шактый иде. Кыш көне төн уртасында җиләк, карбыз таптыру дисеңме, туңдырмадан соң тозлы помидор ашыйсы килүме – берсе дә калмады. Боларны бер дә авырсынмыйча, хәтта бик теләп эшләде ир. Хатыны боларны юри эшләми бит, карынындагы мәхәббәт җимешләре шулай назлана. Кайчандыр әнисе сөйләгән иде аңа: Нияз белән йөкле вакытта үтереп кара карлыган ашыйсы килә башлаган. Урамда кышкы суык. Ул вакытта хәзерге кебек мөмкинлекләр юк. Кайнатма ашаса да, күңеле басылмаган. Шуның истәлеге булып аркасын ике түм-түгәрәк кара миң бизәгән Ниязның. Шуңа да Миләүшәнең теләгән әйберен тиз генә таба алмаса борчыла башлый ул. Балада берәр эз калмасын тагын. Ярый ла, анык кебек аркасына чыкса, ә йөзендә булса? Аллам сакласын!..

Бернинди «бизәксез», сау-сәламәт баһадир булып туды аларның бәхет алмалары. Марат дип исем куштылар. Хатыны бала табу йортына киткәч, борчылудан ни эшләргә белмәгән ир бәби тәпие юарга дип килгән дусларына кафеда табын өчен түләп калдырды да, минем өчен дә эчегез, миндә аракы кайгысы түгел, дип, хастаханә тәрәзәсе төбенә йөгерде.

Эштә берәрсенең баласы туса, йокы туймый, хатын теңкәне корыта, дип зарлана башлыйлар. Нияз өчен исә ул йокысыз төннәр ничектер күңел тынычлыгы гына алып килде. Бик елак булды аларның Маратлары. Берәр әйбер ошамаса, хәзер авызын ачып үкерергә генә тора. Миләүшә дә, көне буе өйдән чыкмыйча, бала янында утырып талчыга, кисәктән кызып китә торганга әйләнде. Ә Нияз сабыр булды. Хатыны кабынып китсә, назлы гына кочагына алып, кайгырма, бәгърем, бар да үтәр, дип тынычландырды. Бала карарга да, өй эшләрендә дә булдыра алганча ярдәм итәргә тырышты. «Син – подкаблучник, хатының сүзеннән чыкмыйсың», – дип көлделәр аннан дуслары. «Әйе шул, – дип уйлый иде ул эченнән генә. – Бәлки, шулайдыр да. Ләкин сезне, үзегез сөйләвегез буенча, чираттагы күңел ачуларыгыздан соң уклау тоткан усал хатын, салкын аш көтә. Ә мине Миләүшәм һәр көнне елмаеп каршы ала». Хатынының йөзендә бәхет чаткысы күрүдән дә зуррак бүләк кирәкми иде иргә. Хәтта кайчак, бала белән ялгызы калып, хатынын иптәш кызлары янына кунакка җибәрә: «Бар, азрак ял итеп кайт, йөзеңнән нур качкан», – дия иде ул аңа.

Декрет ялыннан соң эшкә чыккач, Миләүшә ничектер үзгәрә башлады. Юк кына сәбәптән дә кызып китә торганга әйләнде. Хастаханәдә шәфкать туташы булып эшли иде ул. Элегрәк үз